СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**13 декабрь, 2023 ел** **№ 364**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 02 апрелендәге 68 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы беренче өлешенең 20 пункты, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 33 статьялары, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча 2023 елның 02 декабрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсе, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2023 елның 02 декабрендәге бәяләмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2021 елның 02 апрелендәге 68 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге - Березовка пос. - Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 09 декабрендәге 234 номерлы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге - Березовка пос. - Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 28 апрелендәге 286 номерлы карарларын (07.06.2023 № 300 карары редакциясендә) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).


4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов

**ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ. ЗОНЫ С ОСОБЫМИ УСЛОВИЯМИ ИСПОЛЬЗОВАНИЯ ТЕРРИТОРИИ

М 1:10000



## ПРАВИЛА ЗЕМЛЕПОЛЬЗОВАНИЯ И ЗАСТРОЙКИ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ.ТЕРРИТОРИАЛЬНЫЕ ЗОНЫ

М 1:10000

